# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Тупач торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

18 ноябрь 2025 № 2

2025 елның 20 мартында кабул ителгән Россия Федерациясенең № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 45 нче һәм 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Тупач торак пунктында халык җыены

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге Тупач торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, СВОда катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, һәм СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктыртуын агымдагы ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

2) Тупач торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (юл кырыен һәм аның тирәсендәге территорияне чабу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3) Тупач торак пункты чикләрендә, Гагарин урамы буенча гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

4) Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче

башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су күтәрү манарасына тирәнлек насосы һәм тирәнлек чыбыгы сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Әлеге карарны Коноваловка авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районы сайтына http://menzelinsk/tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Коноваловка авыл җирлеге башлыгы М.Н.Галимҗанов

Исполнительный комитет Коноваловского сельского поселения
ОГРН 1061682001700